**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Карла Маркса, д.1А,
пгт. Камское Устье, 422820

Карл Маркс урамы, 1А йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-00-20, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 5 феврале №60

2026 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2026 елның 28 гыйнварындагы ЛХ-28/280/2026 номерлы хаты һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының "Җирлекләрнең җирләү эше өлкәсендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында" 2024 елның 18 ноябрендәге 220 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә 1,2,3 номерлы кушымталар нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2026 елның 1 февраленнән 9 678, 63 сум (тугыз мең алты йөз җитмеш сигез сум алтмыш өч тиен) күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ю.Сәлимов

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 5 февралендәге 60 номерлы карарына 1 нче кушымта

**2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

(Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда Эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе билгеләнмәгән вафат булганнарны (һәлак булганнарны) җирләүгә)

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 5492,13 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 1294,79 |
| 4.Җирләү | 2891,71 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 5 февралендәге 60 номерлы карарына 2 нче кушымта

**2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

(Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда Эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе билгеләнмәгән вафат булганнарны (һәлак булганнарны) җирләүгә)

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5492,13 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 1294,79 |
| 5. Мәетне җирләү ( кремация ,мәетнең көле салынган урнаны бирү) | 2891,71 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 5 февралендәге 60 номерлы карарына 3 нче кушымта

**2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында ,шәһәр һәм авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| № т/б | Муниципаль берәмлек, шәһәр һәм авыл җирлекләре исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Кама Тамагы штп. | **9 678, 63** |
| 2 | Куйбышев Затоны штп. | |
| 3 | Тенеш штп. | |
| 4 | Балтач авыл җирлеге | |
| 5 | Олы Бортас авыл җирлеге | |
| 6 | Олы Карамалы авыл җирлеге | |
| 7 | Олы Кариле авыл җирлеге | |
| 8 | Олы Салтык авыл җирлеге | |
| 9 | Варварино авыл җирлеге | |
| 10 | Кирельский авыл җирлеге | |
| 11 | Келәнче авыл җирлеге | |
| 12 | Красновидово авыл җирлеге | |
| 13 | Кече Салтык авыл җирлеге | |
| 14 | Осинники авыл җирлеге | |
| 15 | Иске Барыш авыл җирлеге | |
| 16 | Иске Казиле авыл җирлеге | |
| 17 | Сөйки авыл җирлеге | |
| 18 | Тәмте авыл җирлеге | |
| 19 | Уразлы авыл җирлеге | |
| 20 | Яңа Сала авыл җирлеге | |